ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2024 ел Баулы шәһәре №24

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 140 номерлы «Җир кишәрлеген арендага, сатуда милеккә бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 140 номерлы «Җир кишәрлеген арендага, сатуда милеккә бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән”  сүзенең преамбуласында төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 бүлектә «Гомуми нигезләмәләр»:

1.6.пункты белән түбәндәге эчтәлектә өстәргә:

«1.6. Алдан (актив) режимда муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү каралмаган»;

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары»:

2.5.1. пунктның 1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе гражданины паспорты яисә шәхесне раслаучы башка документ, Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән, 2006 елның 27 июлендәге 149 номерлы «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында» Федераль законның 14.1 статьясындагы 18 өлешендә каралган, күпфункцияле үзәкләрдә мәгълүмати технологияләр кулланып»;

2.8.2.1.пунктларда:

4) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җир кишәрлегенә карата капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) мөмкинлеге турында мәгълүмат юк (электр белән тәэмин итү челтәрләреннән тыш), әгәр җир участогын рөхсәт ителгән файдалануга ярашлы рәвештә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаса;»;

13) пунктчада «яки территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителде, аны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы билгеләгән юридик зат тарафыннан тәэмин ителә» сүзләре белән тулыландырырга;

15) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) җир участогы бинаны яки корылманы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм (яки) төбәк инвестиция программасы нигезендә урнаштыру өчен билгеләнгән;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров